ГЛАВА МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«05» июнь 2023 ел № 2

**Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
мәктәп территориясе;
балалар бакчасы территориясе;
парклар, скверлар территориясе;
балалар уен мәйданчыклары территориясе.

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Һадиуллин Илдар Нил улын - хуҗалардан башка терлекләрне элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Сарман районы Мортыштамак авылы Совет ур.47, Совет ур. 34а адреслары буенча урнашкан махсус җиһазланган мәгълүмати стендларда бастырырга һәм Сарман муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (https://sarmanovo. tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (порталда)https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Мортыштамак авыл җирлеге
Советы рәисе И.Н.Һадиуллин